# КАРАР

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче Ике басу Арташ торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

31.10.2024 №1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы «Арташ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Арташ авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына таянып 2024 елның 31 октябрендә узган гражданнар җыенында “ 2025 нче елда Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Ике басу Арташ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?” мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ике басу Арташ торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына вак таш салып ремонтлау (чокырларны) сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләүләр)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегендә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 225 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 117 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучыларның _117_е тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның _0_е тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче Ике басу Арташ торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре - чын мәгънәсендә дип танырга.

2. “2025 нче елда Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Ике басу Арташ торак пунктында Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче Ике басу Арташ торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә" һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ике басу Арташ торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына вак таш салып ремонтлау (чокырларны) сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эш өчен түләүләр) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес

буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлегенең рәсми сайтында: https://saby.tatar.ru/artash адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Арташ авыл җирлеге башлыгы Р.И.Мөхәрләмов